САЛЫМЫҢНЫ ТҮЛӘ

Бурычлы районнарга дәүләт ярдәме күрсәтелмәскә мөмкин

> 2

«ОМЕГА»ГА БАРГАНДА

Грек алфавиты медицинага ничек күчте?

> 3

МАТУРЛЫК ЭЗЛӘҮ

«Китап» радиосы Татарстан һәм Башкортстан буйлап сәфәр чыкты

> 4

КАЗ ӨМӘСЕ:

Шәле кызларыннан эш курка

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 156 (28738) | Сишәмбе | 26 октябрь | 2021 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

Хәтер

Узган атнаның җомгасында Кайбыч районының Борындык авылында чын мәгънәсендә тарихи вакыйга булды. 22 октябрьдә Бөек Ватан сугышында хәбәрсез югалган лейтенант, пулемет взводы командиры, татар солдаты Әбрар Җәләлиевне туган авылына алып кайтып җирләделәр. 1942 елда Калуга өлкәсендәге сугыш хәрәкәтләре вакытында һәлак булган 28 яшьлек улын Борындык авылы елап каршы алды.

Автор фотосы

ҮТӘЛГӘН ВАСЫЯТЬ

ТАТАР СОЛДАТЫ 79 ЕЛДАН СОҢ ТУГАН АВЫЛЫНДА ҖИРЛӘНДЕ

Туган якка ерак юл

4 сентябрьдә «Память» патриотик берләшмәсенең эзләнү эшләре барышында Калуга өлкәсенең Мосальск районының Сухоселино җирлегендә Бөек Ватан сугышында һәлак булган өч сугышчының калдыкларына тап булалар. 1942 елның июль аенда бу тирәдә Варшава шоссесы өчен канкойгыч бәрелешләр барганы билгеле. Биредә ТАССРда оешкан 146 нчы укчылар дивизиясе солдатлары да сугыша. Хәрби документлардан билгеле булганча, 1942 елның 10–20 июль аралыгында бу җирләрдә дүрт меңләп солдат юкка чыккан. Эзтабарлар нәкъ шул урынны өйрәнә башлый. Алдан әйткәнебезчә, казына, эзләнә торгач, өч солдат калдыкларына юлыгалар. Өч кызылармиячене берсендә медальон да була. Соңыннан өч солдатның берсе – пулемет взводы командиры, лейтенант Әбрар Җәләлиев икәне ачыклана. Бу вакытта татар егетенә 28 яшь була.

– Иң кызыгы да шул: медальон кызыл төстә иде. Моңарчы безнең андыйны күргән булмады. Ул бакелит медальон иде. Бәлки, медальонга балавыз агызганнардыр дип тә уйладык, канга буялган төсле дә тоелды, – ди Калуга өлкәсенең конкурентлы сәясәт министры урынбасары, эзләнүләрдә катнашкан эзтабар, хәрби тарихчы Лев Марченков. – Иң элек без аның шлемына юлыктык. Медальондагы язуның бөтен килеш сакланганын күргәч, бик шатландык. 4 сентябрьдә солдатны таптык, икенче көнгә туганнарына хәбәр иттек.

Борындык егете Әбрар Җәләлиев 1914 елда туган. Барлыгы җиде туган: биш ир бала һәм ике кыз булалар. Әбрар – дүртенчесе. Башлангыч белемне авыл мәдрәсәсендә алган. Армиягә 1935 елда ук алына. 1939 елда ул Монголиянең Хәсән-күл һәм Холхин-Гол районнарында Япония милитаристларына каршы сугышларда катнаша. Аннан соң Борындыкка кайта. Бөек Ватан сугышына 1941 елда китә. Аның белән бергә Ватан сагына тагын дүрт туганы да баса. Яу кырында дүртесе кала.

Медальонда солдатның кайдан булуы язылган. Бу мәгълүматны Әбрар Җәләлиев, һәлак булып, кайчан да булса тапсалар, туган авылда җирләрләр дигән өмет белән язган, васыять итеп калдыргандыр, ди эзтабарлар хәзер. Туган авылына аның җәсәде, шәхси әйберләре дә кайтты. Шулар арасында тарак, пәке, портмоне, тәңкә, мундштугы да бар.

Эзтабарларның игътибарын тагын бер нәрсә җәлеп иткән: медальон эчендәге кечкенә кәгазьдә Әбрар Җәләлиевнең кечкенә энесенең исеме дә язылган. «Гадәттә, мондый очраклар өчен солдатлар ата-анасы яисә тормыш иптәшенең исемен күрсәтә. Кәгазьдә күрсәтелгән кешегә исә солдатның үлеме турында хәбәр ителергә тиеш була. Әбрар очрагында бу кеше – энесе. Безнең аңлавыбызча, ул әти-әнисенә мондый кайгылы хәбәрне әйтүләрен теләмәгәндер», – ди Лев Марченков.

Эзтабар әйтүенчә, Әбрар Җәләлиев очрагы – тарих өчен дә, эзләнүчеләр өчен дә уңышлы очрак. Ник дигәндә, буш медальон табып чыгарган чаклар азмыни? «Үлем кәгазе»н язганда, солдат нинди хисләр кичерә икән? Ул бит ни өчен бу сүзләрне язуын аңлый! Солдат медальоны буш булган очраклар аеруча кызганыч… Андыйларны да туган җиренә кайтарасы, гүргә иңдерәсе иде дә бит, булмый. Әбрар исә туган ягына яңа тарих булып кайтты», – ди Лев Марченков.

Өмет сүрелмәгән

Соңгы солдат җирләнмичә, сугыш беткән дип саналмый, дигән мәгълүм сүзләр бар. Әйе, Әбрар Җәләлиев – туган ягына кайтып (79 елдан соң булса да!), тынычлыкны туган туфрагында таба алган сирәкләрнең берсе. Шуңа да мондый вакыйгалар берәүне дә битараф калдырмый. Борындык авылы халкы да солдат кайткан көнне Хәтер көненә тиңләде. Яшьтәшләре, чордашлары инде күптән гүр иясе булса да, аның батырлыгын белгән кешеләр әле бар.

92 яшьлек Талига апа Хәйбуллина Әбрар Җәләлиевне сугышка озатып калганда бала гына була әле.

– Авыл советы безнең өй каршында гына иде. Берәр нәрсә булса, шунда җыела бит инде халык. Солдатка да шуннан киттеләр. Без – бала-чага, мәктәп укучылары. 11 яшьлек булганмындыр, – диде ул. – Әбрар абыйның туган ягына кайтып җирләнәчәген ишеткәч… Бу – бик зур вакыйга! Ничек тапканнар бит! Ул безнең өчен исән-сау кайткан кебек.

Ахыры 3 нче биттә >

Бу кызык!

Әбрар Җәләлиев исеме «Правда» газетасының 1943 елгы бер санында да телгә алына. Биредә «Татар халкының фронтовик татарларга хаты» басыла. Язмада иң батыр солдатлар турында әйтелә. Борындыкның батыр улы турында исә: «Дан һәм хөрмәт сиңа, большевик-пулеметчы Әбрар Җәләлиев! Бер сугышта йөздән артык фашистны юк итеп, син бөтен дөньяга Ватанын саклаучы татар егетенең нинди батырлыкларга сәләтле булуын күрсәттең», – дигән мактау сүзләре бар.

Чаллыда – шартлау

Дүшәмбе кичендә Чаллының Татарстан урамында урнашкан торак йортта шартлау булды. Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы хәбәр итүенчә, 5 катлы йортның 4 нче катында урнашкан фатирда газ шартлаган дип фаразлана. 1979 елда төзелгән бинаның бер өлеше җимерелгән – йортның дүртенче һәм бишенче катларындагы 8 фатир зыян күргән.

Куркыныч вакыйга булган йорттан 32 кешене эвакуацияләгәннәр. Йортта яшәүчеләрне каладагы кунакханәләрнең берсенә урнаштырганнар. Газетабыз басмаханәгә тапшырылганда 7 кешенең коткарылуы турында хәбәр бар иде. Араларында балалар да бар. Һәлак булучылар турында мәгълүмат юк.

Чаллыдагы шартлау буенча хокук сакчылары тикшерү уздыра, җинаять эше кузгатылган. Татарстан Президенты кушуы буенча, вакыйга урынына Премьер-министр Алексей Песошин һәм сәламәтлек саклау министры Марат Садыйков китте. Вакыйга турында тулы язманы газетабызның киләсе санында укый аласыз.

tatarstan.ru

Каникул озайтылмаячак

Каникулдан соң мәктәп укучыларын өйдә торып укуга җибәрү күздә тотылмый. Бу хакта Россия мәгърифәт министры Сергей Кравцов белдергән. Министр сүзләренә караганда, илдә Президент Указы белән 30 октябрьдән 7 ноябрьгә кадәр игълан ителгән ял көннәре каникул чорына туры килә. Әмма моңа карап балаларның ялы озайтылмаячак, уку планнары үзгәртелмәяәк, дигән ул. Бу хакта РИА «Новости» яза.

Кичә «Роспотребнадзор»ның Татарстандагы идарәсе дә балаларның дистанцияле укытуга күчерелмәячәген белдерде.

Сүз уңаеннан, моннан берничә көн элегрәк мәгърифәт министрының беренче урынбасары Александр Бугаев мәктәпләрнең «ковид яллары» чорыннан алданрак каникулга китә алуы турында сөйләгән иде.

Көн кадагында

Президент әйтте

КОРОНАВИРУСКА БӘЙЛЕ ЧИКЛӘҮ ЧАРАЛАРЫ КАТГЫЙЛАНА

Ил буенча барган вазгыять катгый адымнар ясарга мәҗбүр итә. Моңа бәйле рәвештә Россия Президенты Владимир Путин Хөкүмәт әгъзалары белән киңәшмә вакытында тәкъдимнәрен җиткерде. Алар кемгә кагыла һәм хакимият алдында нинди бурычлар тора? Төп мәгълүматны тупладык.

◆Хөкүмәт дәүләт казнасы хисабына коронавирус белән авыручыларны стационар дәвалау өчен кыйммәтле дарулар сатып алу һәм төбәкләргә китертүне тәэмин итәргә тиеш була. Моннан тыш даруларның, кислородның җитәрлек күләмдә булуын тәүлек буе күзәтү бурычы куела.

◆Хөкүмәткә санитар-эпидемиологик вазгыять киеренке булган төбәкләргә Оборона, Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы һәм башка федераль министрлыклар белән берлектә ярдәм итәргә йөкләмә бирелде. Коронавирус белән авыручылар күп булган төбәкләргә илнең әйдәп баручы медицина һәм фәнни оешма белгечләре бригадаларын җибәрергә туры киләчәк.

◆Министрлар Кабинеты, төбәк хакимияте белән берлектә, коронавируска каршы тест тапшыру күләмен бермә-бер арттырырга, экспресс-тест белән тәэмин итәргә тиеш була. Шул ук вакытта вакцинация һәм кабат вакцинация ясату күрсәткечләрен дә арттыру бурычы тора. Бигрәк тә хроник чирләре булганнарга һәм 60 яшьтән өлкәнрәкләргә аерым игътибар бирү таләп ителә. Моннан тыш гриппка каршы прививка кадату эшен дә көчәйтү сорала.

◆Коронавирус белән авыручы яки чиргә шиге булганнарга «больничный» бирүне оештырырга, шулай ук алар белән элемтәдә булган кешеләрне дәвалау, аларның үзизоляция режимын үтәвен контрольдә тоту кирәклегенә игътибар итте.

◆Төбәк җитәкчеләре, Роспотребнадзор вәкилләре белән берлектә, барлык транспорт чараларында да санитар-эпидемиологик чикләүләрнең үтәлешен җитди контрольдә тотарга тиеш була. Дезинфекцияләү эшен тәэмин итәргә кирәклегенә дә басым ясалды. Кафе-ресторан, күңел ачу чараларының эше төнге 11дән иртәнге 6га кадәр чикләнәчәк.

◆Кайбер оешмаларга керүне коронавируска каршы вакцинацияне раслаучы документы булганда гына рөхсәт итмәкчеләр. Вакцина ясатырга ярамаганнарның кулында шул хакта белешмәсе булу шарт. Оешмалар исемлеген хөкүмәт һәм төбәк хакимияте үзе билгеләячәк.

◆60 яшьтән өлкәнрәк, вакцина ясатмаган кешеләргә үзизоляция режимын сакларга киңәш ителде. Коронавируска каршы вакцина ясаткан хезмәткәрләргә исә хезмәт хакын саклап калу шарты белән ике көнлек ял бирү тәкъдим ителде. Вакцинадан соң иммунитет барлыкка килсен өчен, хроник авырулары булган һәм 60 яшьтән өлкәнрәк хезмәткәрләрне читтән торып эшләү режимына күчерергә дигән киңәш бирелде.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Татармын! Горурмын!

Мәхмүт ХӘСӘНОВ, язучы, Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе:

Туган телен сансызлаган үзе дә сансыз. Иң яманы – ана сөте белән кергән изге, иң күркәм гореф-гадәтләребезне әкренләп югалта баруыбызда. Кеше өчен иң каһәрле, каргышлы язмыш – милли горурлык хисенең үтерелүе.

РОССИЯДӘ ФӘН һӘМ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР

Мәскәү, Санкт-Петербург һәм Татарстан Россиядә фән һәм технологияләр үсеше буенча иң алдынгы төбәкләр санала. РИА «Новости» белгечләре исәплән чыгарганча, илдә җитештерелгән инновацияле товарларның 30 проценты әнә шул өч төбәк өлешенә туры килә.

2020 ел нәтиҗәсе	Төбәк	Рейтинг күрсәткече	2019 ел нәтиҗәсе
1	Мәскәү	78,43	1
2	Санкт-Петербург	76,06	2
3	Татарстан Р.	68,83	4
4	Түбән Новгород	67,52	3
5...	Мәскәү өлкәсе	64,84	5
...81	Карачай-Черкесс Р.	14,19	79
82	Чечня Р.	13,26	80
83	Хакасия Р.	12,34	81
84	Ненец АО	11,75	84
85	Ингушетия Р.	9,35	85

Ярма бәясе арта

Ноябрь аенда карабодай, солы ярмасы, геркулес кыйммәтләнергә мөмкин. Ярма бәясенең 10–20 процентка артуы күздә тотыла. Бу хакта «Коммерсантъ» ярма җитештерүчеләр мәгълүматларына таянып хәбәр итә. Аерым алганда, карабодай кыйммәтләнү Алтай краенда культураның уңмавына бәйле: биредә җитештерүчеләрдә бер кило ярма бәясе бер ел эчендә 57 сумнан 80 сумга җиткән. 1 октябрьдән 15 октябрьгә кадәр төбәктә карабодай хакы – 38, солы – 32, арпа 36 процентка арткан. Белгечләр базарга яңа уңыш алынгач кына хәлләрнең берникадәр яхшыруын көтә. Ярма җитештерүнең үзкыйммәте дә үсә. «АФГ Националь» агрохолдингы вәкиле әйтүенчә, соңгы елда полипропилен һәм катыргы капның бәясе – 100 проценттан күбрәккә, ә чимал бәясе 30 процентка арткан.

Үз чиратында, Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгында 2020 елдагы табыш хисабына азык-төлек җитештерүчеләрнең продукциясе кыйммәтләнүне булдырмаска тырышуларын билгеләп үткәннәр.

Түләү үзгәрми

Казанда машина кую урыннарының ташламалы эш режимы ел азагына кадәр озайтыла. Шәһәр мэры Илсур Метшин «эшлекле дүшәмбе» утырышында шулай дигән. Эш көннәрендә генә, иртәнге 7дән кичке 6га кадәр, парковка өчен түләү алына, дигән сүз бу. Калган вакытта – шимбә, якшәмбе, бәйрәм көннәрендә машина кую өчен түләргә кирәкми. Исегезгә төшерәбез: шәһәрдә парковкаларның ташламалы эш режимы берничә тапкыр озайтылды. Соңгы тапкыр – 30 октябрьгә кадәр.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ТӨРЕКЧӘ ИЛЧЕ КУУ

Илләр белән илләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә тотрыклылык югалу, конфликтлар үсеше дөнья сәясәтендә төп вектор булып калуын дәвам итә. Үткән атнада төрек лидеры Эрдоган яңадан дөнья шаулатты. Бердән, ул БМОның Куркынычсызлык советында берничә илнең вето салу хокукын тәнкыйтьләп, үзен дөнья кендеге дип санаган держава лидерларының кытыгына тиде. Африка, Азия һәм дөньяның башка почмакларында төрек йогынтысын көчәйтү белән мәшгуль булган Әнкараны берничә башкаларның дөнья тәртибен билгеләве канәгатьләндерми. Төрекләр актив рәвештә Африка илләрен һәм башка элекке колониаль дәүләтләрне атаклы Байрактар дроннары белән коралландыралар һәм глобаль капитализмның канлы тырнакларыннан ычкынырга өндиләр. Шунысы кызык: Куркынычсызлык советында вето салу хокукына ия булган Россия дипломатиясе аның фикерләрен яклый.

Атна ахырында Эрдоган тагын бер зур таш атып, сәясәт диңгезендә зур дулкын кузгалтты: ун дәүләт илчесен Төркиядән куып, үз илләренә кайтарып җибәрде. Нииндидер бер атташелар яисә гади дипломатлар гына түгел, ә Америка, Канада, Франция, Германия, Швеция, Норвегия, Нидерланд, Дания, Финляндия һәм Яңа Зеландия илчеләре чемоданнарын тутырырга мәҗбүр булдылар. Дөнья дипломатиясендә гадәттән тыш хәл булды. Дипломатларның артларына тибүнең сәбәбе аларның Госман Кавалы дигән бизнесмен һәм хокук яклаучыны азат итүгә чакырулары булды. Кавалы исә 4 ел элек дәүләт түнтәрелеше әзерләүдә гаепләнеп кулга алынган иде. Көнбатышлыларның башка илләрне ничек яшәргә өйрәтүләре чикләрне белми, әлбәттә. Янкилар җитәкчелегендәге коалиция ил лидерларына сәяси басым ясарга ярата, алай гына барып чыкмаса, дәүләт түнтәрелешләре оештырырга, анысы да нәтиҗәне бирмәсә, сугыш башларга да күп сорамый һәм үзләренең моңа хакы бар дип саный. 2016 елгы барып чыкмаган дәүләт түнтәрелеше Эрдоганның рейтингы бик зур булуын, аның идарәсен какшату кыен икәнлеген күрсәтте. Әмма океан артында үзләре белән конфликтка кергән лидерларны юлдан алып ташлау идеясеннән беркайчан да баш тартмыйлар. Эрдоган исә аларның тамагына утырган зур сөяккә әверелде һәм бу соңгы демарш – илчеләрне куу аңа кыйбатка төшәргә мөмкин, диләр. Төркиянең үз эчендә идея көрәше, хакимлек өчен тарткалашу бик кискен бара. Харизмасы белән күпләрнең симпатиясен яулап алган лидер инде шактый ук картайды. 2023 елда аны хакимлектән читләштерү теләге бер оппозициянең генә түгел, аңа финанс һәм әхлакый ярдәм күрсәтүче Көнбатыштагы хуҗаларның да зур хыялына әверелде. Сәяси күзәтүчеләрнең бер өлеше, Эрдоган бу батырлыгы белән популярлыгын көчәйтергә теләде, дигән бәя дә бирә.

Дүшәмбе иртәсендә генә Суданнан хәбәр килеп төште: дәүләт түнтәрелеше омтылышы барып чыкмады, диләр. Хартумда хәл бик кызык: хакимиятне саклыйбыз дип, анда зур дәүләт чиновникларын кулга алалар. Ил Премьер-министрының йорты хәрбиләр тарафыннан чолганыш хәлендә һәм хөкүмәт җитәкчесе үзе йорт сагы астында. Кемнең фетнәче икәнен дә аңлау кыен. Бу – вакыйгаларның безгә күренгән тышкы ягы гына, ә сәхнә артында американнар тора. Шулай булгач, Эрдоган чыгарган гадәттән тыш җәнҗалга гаҗәпләнергә кирәкми.

Россиядә

ПРОЦЕНТЛАР БЕЛӘН УЙНАУ ДӘВАМ ИТӘ

Җомга көнне Россиянең Үзәк Банкы быел инде алтынчы тапкыр төп ставканы күтәрде. Процентларның югарыга таба сикерәсе мәгълүм иде инде. Әмма бер генә белгеч тә сикереш темпын алдан дөрес итеп фаразлый алмады. Берәүләр 0,25 процентлык адым, икенчеләр 0,5 процентка күтәрелү көткәннәр иде. Үзәк Банк җитәкчесе Эльвира Нәбиуллина утырышка ук куелган җәя рәвешендәге брошка тагып килде. Төп банкирның изүендәге бизәнү әйберсе символ теле белән аның ниятләре турында сөйли. Моны финанс дөньясы белән азмы-күпме таныш булган һәркем белә. Менә бу ук-җәяне «Российская газета» Үзәк Банкның еллык инфляцияне 4 процентка калдыру омтылышын гәүдәләндерә дип бәяләде. Символны башкачарак та аңлап була: төп ставка киләчәктә атылган ук тизлегендә югарыга омтылырга мөмкин дисәң дә ялгыш булмас, мөгаен. Хәер, Үзәк Банк өчен болар икесе дә бер үк нәрсә: төп ставканы күтәрү инфляция күрсәткечләрен түбәнәйтә дип саныйлар. Ул фикердә мантыйк бар инде бераз. Үзәк Банк ставкасы күтәрелгәч, коммерция банклары да кертемнәргә процентларны арттыра һәм халык, акчасын тоту урынына, аны депозитларга илтә башлый. Ихтыяҗ кимү бәяләрне төшерә. Халыкның кулында депозитка илтерлек акча булмаса да, процент ставкасы ихтыяҗны киметүдәге үз ролен уйный барыбер. Зур ставкалы кредит алу куркыныч була башлый, бурычка алып товар ташучылар, фатир алучылар саны кими. Нәтиҗәдә бәяләр төшә. Әмма дә ләкин аксак мантыйк бу. Бәяләрнең төшүе булса да, вакытлыча гына. Сәнәгать предприятиеләре дә, хезмәт күрсәтү бизнесы да, авыл хуҗалыгы да эшне бурычка алып оештыралар бит. Процент күтәрелгәч, аларның да кредит алу мөмкинлеге кәгәя. Я зур ставка белән кредит аласың да үзкыйммәтне күтәрәсең. Үзкыйммәт күтәрелгәч, бәя дә борыннан тартып үстерүне сорый. Ә ихтыяҗ юк. Югары бәягә дә, түбән бәягә дә халык товар алырга теләми, чөнки я акчасын депозитка илтә, я акчасы булмаса, кредит алырга курка дип уйлыйк инде. Ихтыяҗ булмагач, бизнес нишли? Бер өлеше тәртәсен кире бора, ягъни ябыла; исән калганнары, гафу итегез, бәяләрне күтәрергә мәҗбүр булалар. Көндәшләрнең кимүе аларга булыша, чөнки аз ихтыяҗ һәм югары бәяләр фонында дефицит пәйда була башлый. Үзәк Банкта монысын финансчылар проблемасы түгел, җитештерүчеләр проблемасы дип саныйлар. Сәнәгать җитештерүе һәм икътисади үсеш өчен җавап бирүче министрлар тыз-быз килә башлыйлар инде шуннан соң. Үзәк Банк белән конфликта кереп булмый, сәясәтчеләр теле белән әйтсәк, бу «контрпродуктив», шуңа күрә алар үз тармакларында кредитларны субсидияләү идеясен алга этәрә башлыйлар. Бөтен тармаклар да берьюлы оттыра: өстенлекле кредитларга бюджеттан байтак акча бүләсе була, кредитоманнар саны артырга тиеш була, берникадәр тынлыктан соң бәяләр яңадан югары чөелә, депозитка кергән акчаны зуррак процентлар белән кайтарып бирәсе була һәм алар тагын инфляциягә үз өлешләрен кертәләр… Бу уенда бары тик банкирлар гына ота. Ә без барыбыз да оттырабыз.

АСЫЛЫН АҢЛЫЙСЫ ИДЕ

ТР Дәүләт Советында

Парламентның 26 нчы утырышы көн тәртибендә иң әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе, әлбәттә инде, Татарстанның 2022 елга һәм 2023–2024 елгы план чорына бюджет проектын тикшерү иде. Бу аңлашыла да, чөнки ил, Татарстан икътисадында чагыштырмача тотрыклылык, алай гына да түгел, җанлану, хәтта үсеш күзәтелә дип сөйләсәләр дә, пандемия афәтенә бәйле икәнлегебез һәр чыгышта диярлек сизелде.

Президент Рөстәм Миңнеханов Дәүсоветка юллаган төп акча документы бөтен комитетларда каралды, парламент тыңлаулары узды, барлык муниципалитетлар катнашында республика киңәшмәсе үтте, әмма сораулар һаман кала бирде. Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты рәисе Леонид Якунин әйтүенчә, закон проектын тикшерүдә иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре, аерым гражданнар, гомумән алганда, 800ләп кеше катнашкан. Аларга парламенттагы сәяси партия вәкилләре дә кушылды.

Татарстанның финанс министры Радик Гайзатуллинның чыгышыннан соң депутатлар сорау арты сорау яудырдылар. Юкса аңа хәтле икътисад министры Мидхәт Шаһиәхмәтов та бюджетка кергән һәм чыккан һәр тиен турында аермачык сөйләп биргән иде.

Радик Гайзатуллин әйтүенчә, акча документы Конституция, Бюджет кодексы таләпләренә туры китереп эшләнгән, федераль законнар да исәпкә алынган. Бюджет кеременең 60 проценты – эре предприятиеләр салымы акчасы. Социаль өлкәгә акча арткан-нан-арта бара. Ә гомумән алганда, социаль әһәмиятле һәм беренче чиратта хәл ителергә тиешле мәсьәләләргә тотылачак акча бөтен чыгымнарның 80 процентын тәшкил итәчәк. Киләсе елга бюджет кереме 2001 елгы план күрсәткечләре белән чагыштырганда 7,3 процентка артып, 294,8 млрд сумга җитәчәк. Керем арта икән, акча нинди максатларга тотылыр соң? Депутат Камил Нугаевны балалар лагерьлары төзү һәм ремонтлау эшләрен киләсе елда да дәвам итү мәсьәләсе кызыксындырды һәм ул министрдан уңай җавап ишетте.

Нефть һәм нефть-химия тармагының табышка салымы бюджетның күпме өлешен тәэмин итә соң? Бу мәсьәлә депутат Марат Галиевны кызыксындыра иде. «50 процент чамасы», – диде Радик Гайзатуллин. Марат Галиев мондый сорауны юкка гына бирмәгәндер, чөнки илдә дә, Татарстанда да «нефть энәсе»ннән төшеп, җитештерүнең төрле тармакларын үстерүгә омтылыш бара. Депутат Камил Садриев депутатларның сайлау алдыннан халыкка биргән вәгъдәләрен искә төшерде, халык наказларын үтәр өчен бюджетта акча каралмы, диде. Финанс министры әйтүенчә, бүген төрле программалар өчен акча бүлү бара икән. Бу эш муниципалитетлар белән бергә килешеп башкарыла, наказлар исәпкә алыначак.

Комитет рәисе Айрат Зарипов мәктәп ашханәләрен заманча үзгәртү, тагын да уңайлырак итү программасы туктап калмасмы, дип борчыла иде. Бу эш тә дәвам итәчәк, бюджетка бер миллиард сум тирәсе акча салынган инде, дип җавап бирде Радик Гайзатуллин.

КПРФ фракциясе җитәкчесе Хафиз Миргалимов аерым сүз алып чыгыш ясады. Нотыгын Россия Президентының капитализмга биргән бәясеннән башлады ул. Владимир Путин шушы көннәрдә генә капиталистик стройның барыбер бетәчәгенә ишарә ясаган иде. Аның «хәерчелек – Россиянең төп дошманы» дип әйткәннәрен дә искә төшерде Хафиз иптәш. Халыкның уртача кереме кимүен, хезмәт хаклары, пенсияләр аз булуын да онытмады. Кыскасы, КПРФ депутатлары бюджет проектына җитмешләп үзгәреш-өстәмә тәкъдим итмәкчеләр, бу тәкъдимнәр халыктан җыелган икән.

Алар бюджетта чагылыш табармы-юкмы, тәгаен генә әйтү кыен. Бюджет турындагы закон проекты әлегә беренче укылышта гына кабул ителде. Депутатлар 5 ноябрьгә хәтле бар уйларын кәгазьгә төшереп, бюджет эшләүчеләргә тәкъдим итә алалар. Ә закон проекты 15 ноябрьдә яңадан каралачак. Әле коронавирус нишләр, аның белән бәйле чикләүләр икътисадның кай җиренә сугар – монысына төгәл җавап була да алмый. Шуңа күрә бюджет та – фараз гына, шулай да тормышка ашардай фараз дип уйлыйк.

Бюджет проектына Хисап палатасы рәисе Альберт Вәлиев бәя бирде. Ул да фаразланган керемнәр күләме чыгымнарны капларлык дигән фикердә. Шуның өстенә бюджет кытлыгын каплар өчен үз мөмкинлекләребез дә җитәрлек икән. Парламент рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да, бюджетның, коронавирус белән бәйле киеренке шартларда эшләнсә дә, баланслы булуын әйтте. Ягъни акча документы бик уйланылган, керем һәм чыгым өлешләрендә артык аерма юк.

Утырыш башында кузгатылган бер мәсьәлә аерым игътибарга лаек дип уйлыйбыз. Ул инде ничә еллар буе сөйрәлеп килгән «койрыклы» проблема. Мәскәүдә яңадан милли республикаларда «Президент» атамасын бетерү турында сүз куерта башладылар. Парламент утырышында исә «Россия субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» федераль закон проекты хупланмады.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин исә әлеге документ Россия Конституциясе нормаларына каршы килә дип белдерде. «Хәзер бу теманы күтәрәсем килмәгән иде, – диде ул тәнәфестән соң. – Инде утырыш тәнәфесендә үк телефоннан шалтырата башладылар, газеталарда язалар. Асылын аңламаганнар. Югары вазыйфаи затның атамасы үзгәрүдән түгел… Бу закон проекты, Россия Конституциясенең гамәлдәге нормаларын бозып, субъектларның вәкаләтләренә бик нык кагыла, безне бу нормаларны бозарга мәҗбүр итә».

Фәрит Мөхәммәтшин аңлатып үткәнчә, закон проекты Дәүләт Думасында беренче укылышта карап тикшерелгәннән соң, документ республика Дәүләт Советына алынып, Татарстан депутатлары аны яңадан караячак. «Республика парламентының бүгенге мөнәсәбәте һәм тәкъдим ителгән закон проектының кире кагылуы аңа җитди үзгәрешләр кертү мөмкинлеге бирәсенә ышанам», – дип билгеләп үтте ул.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе депутат, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулланың «әлеге закон дәүләтебезнең федераль төзелешен ярым-йорты регламентлаган Россия субъектларының законнар чыгару һәм башкарма хакимиятенең гомуми принципларын алыштырачак» дип чыгыш ясавына бәйле рәвештә шулай дип аңлатып үтте.

«Россия субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» федераль закон проектын сенатор Андрей Клишас һәм Дәүләт Думасы депутаты Павел Крашенинников керткән иде.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Әҗәтлегә ярдәм булмаячак

Икътисадтагы сизелерлек уңай үзгәрешләр җиңел сулап куяр өчен сәбәп түгел. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашында Министрлар Кабинетында финанс, казначылык һәм салым органнары киңәшмәсе үтте. Алар бу елның 9 ае өчен хисап тотты.

Ел башында икътисади күрсәткечләр сөендергән. Татарстан Президенты белдергәнчә, тулай төбәк продукты үсеше 102,9 процент тәшкил иткән, сәнәгать җитештерүе индексы – 105,2, төзелештә үсеш 103,7 процентка җиткән. Тугыз айда үз керемнәребез 232,4 млрд сум булган. Моңа да карамастан, республика җитәкчесе, тынычланырга иртәрәк, дип тә кисәтте. Икътисади вазгыять тә киеренке кала.

– Эшләвебезне чикләү шартларында дәвам итәбез, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Республика парламентына 2022 елгы бюджет проекты кертелде. Ул беренче тапкыр 11 млрд сумлык дефицит белән оешты.

Президент районнардагы салым буенча бурычларны булдырмау мәсьәләсенә аерым туктады. Кире очракта муниципалитетлар республика ярдәменнән колак кагарга мөмкин.

– Киләсе елдан башлап, районнарда салым буенча бурычлар артса яисә җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең әҗәтләре булган очракта, без республика бюджетыннан төрле чаралар оештыру һәм капиталь максатларга матди ярдәмне кыскарту мәсьәләсен караячакбыз. Башкача була алмый. Үзегез начар эшлисез икән, нинди өстәмә ярдәм булсын ди? Шуңа күрә бу сорауга җитди игътибар бирегез, – дип кисәтте ул.

Гомумән, 1 октябрьгә бирелгән мәгълүматка караганда, республикада салым буенча бурыч күләме 7,8 млрд сумны тәшкил итә. Узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, бу 602 млн сумга кимрәк. «Җиңел эш түгел, әмма нәтиҗәсе күренә. Без әҗәтләрнең артуына юл куймадык. Билгеле бер кимү бар», – диде Татарстан Президенты.

Физик затларның салым бурычы 1,8 млрд сумга җиткән. Президент бу җәһәттән аңлату эшләрен алып барырга, халык белән эшләүне активлаштырырга кирәклеген искәртте.

Бюджет нинди генә булмасын, социаль әһәмияткә ия максатлар турында онытырга ярамый. Президент әйтүенчә, илкүләм проектларны тормышка ашыру өчен дә шактый акча кирәк. «Быел без бу максатларга 31,3 млрд сум акча бүлеп бирәчәкбез. Шуның 8,1 млрд сумы – республика бюджетыннан», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Сан

- Татарстанның салым җыю хезмәте вәкилләре ел азагына **1** трлн сум күләмдә салым җыеп булыр дип өметләнә. Ел башыннан бюджетның барлык дәрәҗәләренә **785,6** млрд сумлык салым түләүләре кучкән. Бу пандемиягә кадәрге **2019** ел күрсәткечләре белән чагыштырганда, **319,7** млрд сумга күбрәк.
- Салымның **70** проценттан артыгы – федераль (**551** млрд), калганы (**233,7** млрд) республика казнасына кучкән.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме алтынчы утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ:**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы егерме алтынчы утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясын сайлау турында.
2. «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 1256381-7 номерлы федераль закон проекты хакында.
3. И.С. Вольфсонның, Т.П. Ларионованың, М.Г. Нуриевның, А.В. Прокофьевның Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында.
4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының аерым комитетлары составына һәм Керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында.
5. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы составына үзгәрешләр кертү турында.
6. «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 238-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
7. «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 237-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
8. «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 243-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
9. «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 242-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
10. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 206-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
11. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 232-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
12. «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 231-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
13. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы закон актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 239-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
14. «Татарстан Республикасы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының үз көчен югалтуын тану хакында» 234-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
15. «Гражданнарның гаражларга һәм алар урнашкан җир кишәрлекләренә хокуклар алуына бәйле аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 244-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
16. «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 2^1 статьяларына һәм «Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 241-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
17. «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» 235-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
18. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларын төзү турында» 2019 елның 20 сентябрендәге 12-VI ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында.
19. «Юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны дәүләт теркәве турында» Федераль законның 22^1 һәм 22^2 статьяларына һәм «Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте транспорты уставы» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 1256975-7 номерлы федераль закон проекты турында (авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр өчен хөкем ителгәнлеге бетерелмәгән һәм исәптән төшерелмәгән затларга пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруны тыю хакында).
20. «Җылылык белән тәэмин итү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 1252382-7 номерлы федераль закон проекты турында (җылылык белән тәэмин итүнең (кайнар су белән тәэмин итүнең) ачык системаларын, мондый системаларның аерым участокларын кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системаларына күчерү буенча чараларның икътисади нәтиҗәлелеген мәҗбүри бәяләүне үткәрү өлешендә).
21. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1256984-7 номерлы федераль закон проекты турында (юл хәрәкәте иминлеге өлкәсендә хокук бозулар өчен штрафлар түләмәгән чит ил йөртүчесенең транспорт чарасын тоткарлау мөмкинлеге хакында).
22. «Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 51 бүлегенә үзгәреш кертү турында» 1256989-7 номерлы федераль закон проекты хакында (авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр өчен хөкем ителгәнлеге бетерелмәгән затларга таксида эшләүне һәм пассажирлар йөртү белән шөгыльләнүне тыюны билгеләү өлешендә).
23. Төрлесеннән.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2021 елның 25 октябре
№ 1146-VI ДС

Татарстан Республикасы җәмәгать судьясын сайлау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы итеп өч елга түбәндәгене сайларга:

Татарстан Республикасы Зәй суд районы буенча:
2 нче суд участогына – Минһаҗев Айзат Ринат улын.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2021 елның 25 октябре
№ 1147-VI ДС

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы составына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы составыннан Ларионова Татьяна Петровнаны чыгарырга.
2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы әгъзасы итеп Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Кузьмичева Елена Ивановнаны сайларга.
3. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумын сайлау турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2019 елның 20 сентябрендәге 29-VI ДС номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 1 пунктта «, Ларионова Татьяна Петровнаны» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 пунктта «түбәндәге депутатларын сайларга:» сүзләреннән соң «Кузьмичева Елена Ивановнаны» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2021 елның 25 октябре
№ 1154-VI ДС

КОРОНАВИРУСЛЫ СЫРХАУЛАР БЕЛӘН ЭШЛӘҮЧЕ ТАБИБ:

«ТУКТАП ТОРЫРГА ВАКЫТЫБЫЗ ДА, ХАКЫБЫЗ ДА ЮК!»

«Татар-информ» / Владимир Васильев

Коронавирус инфекциясе күптән инде «шәһәр чире» булудан туктады. Хәзер аның белән авыручылар район-авылларда да шактый. Бу юлы вазгыятьнең нинди булуын Кайбыч районындагы вакытлыча ачылган коронавируслы сырхауларны дәвалый торган бүлек мисалында карарбыз. Район үзәк хастаханәсе баш табибы Гөлнара САФИУЛЛИНА белән шул хакта сөйләштек. Табибә үзе дә гел сырхаулар янында. Без аралашканда да вакыты чикле иде...

:: Гөлнара Илдусовна, Кайбыч районы пандемияне ничек кичерә? Кыска вакыт эчендә яңа инфекцияне дәвалау эшенә күчү авыр булдымы?

– Кайбычтагы коронавируслы сырхауларны дәвалый торган бүлек ачылганга бер елдан артык вакыт узды. Эшли башлаган чорда эш шартларына, киемнәргә ияләшү авыррак булса, хәзер инде анысын да көндәлек эш киеме сыман кабул итәбез. Бик тиз генә озатырга теләсәк тә, мәкерле авыру әле бүген дә чигенергә уйламый. Пандемия чорында тупланган тәҗрибә безнең өчен бик кыйммәтле. Авыр булса да, кирәкле ул. Без билгесезлек эчендә, гадәти булмаган шартларда, тиз вакыт аралыгында эш режимын үзгәртергә өйрәндек. Хәзерге вазгыять тизлек таләп итә, барысына да яраклашуны, барлык сынауларга әзер булуны сорый. Безнең туктап торырга вакытыбыз да, хакыбыз да юк!

:: Беренче сырхауны хәтерлисезме?

– Узган елның 30 апреле иде ул. Мәскәүдән кайтучы, вахтовик булып йөрүче 30 яшьлек ир-ат. Аннары Чүти авылына кайткан бер хатын-кызны дәваладык. Шуннан башланды инде...

:: Аннан үзегездә дә госпиталь ачылды...

– 9 октябрьдә вакытлыча госпиталь булдыру турында карар булды. Хәзерге вакытта 17 урынлы госпитальдә 15 кеше ята. Шуларның өчесе үпкәне ясалма вентиляцияләү аппаратына тоташкан, кислород белән сулаучылар да бар. 2020 елның 10 октябреннән башлап барлыгы 340 кеше дәваланып чыкты. Кызганыч, республиканың башка районнарындагы кебек үк, үлем очраклары бездә дә булды. Туганнарына, якыннарына кайгылы хәбәр җиткерү бик авыр. Моны эшебезнең иң авыр минуты дип саныйм мин. Еш кына «йокыларыннан уянсыннар инде» дип көтеп, йөрәк өзелеп утырган вакытлар да була. Шәфкать туташларыбызның битлек астындагы күз яшьләрен сөртеп алулары әле дә күз алдымда тора... Госпитальдә 17 кеше эшлибез. Чир йоктыручылар арасында күбрәк урта, өлкән яшьтәгеләр. Соңгы арада яшьләрне дә госпитальгә салырга туры килә. Коронавирус инфекциясе көннән-көн үзгәрә. Шуңа да карамастан, үлем очраклары урта яшьтәгеләргә туры килә.

:: Хәзер бар җирдә дә вакцина ясату кампаниясе бара. Кайбычта бу җәһәттән нинди күрсәткечләр?

– Хәзерге вакытта район халкының 50,7 проценты прививка ясатты. Планда – 8502 кеше. Соңгы арада вакцина ясатырга теләүчеләр саны 2–3 мәртәбә артты. Тиз арада иммунитет туплап, грипп шикелле генә искә алырлык авыру булып, үткәндә калсын иде дип ышанасы килә. Үзегезне һәм якыннарыгызны саклагыз!

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

«ОМЕГА»ГА КҮПМЕ КАЛДЫ,

ЯКИ КӨТҮНЕ ПЫЧРАТУЧЫ СЫЕРЛАР ХАКЫНДА

Кешелек көрәштә бүген. Күзгә күренмәгән дөнья белән бәрелешнең туктарга исәбе юк. Зурлыгы уртача 100 нанометр, ягъни 0,1 микрон, тагын да аңлаешлырак булсын дигәндә – 0,0001 миллиметрлы таҗлы-капшавычлы шарчыклар, коточкыч тизлектә үрчеп, шактый тиз арада дөньяны басып алды да, миллионнарның тормышын катлауландырып кына калмады, инде менә ел ярым буе, көн туса, яңа корбаннар сорап һәм дә алып тора. Зәхмәт айдан-айга үзгәрә килә, әшәкеләнә. Альфа, бета, гамма, дельта-вируслар. Соңгысы – дельта дигән явызы, калган «юаш»ларны кысрыклады да азынышмы азына бүген. Ул гынамы? Шушы атнада гына ул үзеннән әшәкерәк «бәберчен»ен тудырды. Хәзер анысы да үрчеп маташа.


kzn.ru

Грек алфавитында альфадан алып омегага кадәр – җәмгысы 24 хәреф. Моңарчы бары физикада, математикада кулланылган билгеләр. Кем уйлаган алар медицинага күчәр, гади халык теленә керер дип. Болай барса, грекларның борынгы ул алфавитын ятлап бетермәбезме? Һәр билге – яңа дулкын. Һәр яңа дулкын элеккесенә караганда дәһшәтлерәк. Дәрдмәндне бераз гына үзгәртеп, «Нинди юллар, кайсы дулкын тарта безне җан сорап» диярсең, валлаһи. Мин бу юлларны язганда йоктыручылар һәм үлүчеләр саны буенча илдә яңа антирекорд ялганын әйттеләр. Таҗлы ул хәшәрәт, аның дельта дигәне, Россиядә көн саен бер меңнән артык кешенең гомерен ала башлады. Киләчәктә ни булыр? Чираттагы, бишенче хәреф безнең әлифбадагы Ега тәңгәл, ягъни «эпсилон». Җәй азагында j («йота») дигән штамм хакында да сүз нык куерып киткән иде. «Таралган, «дельта» урынын алган очракта үлем-китем ике тапкыр артачак», – дип куркыттылар. Бәхетебезгә, бәндәне теге дөньяга башкалардан остарак озатучы ул вирус йогышлылык ягыннан башка «туган»нарыннан шактый калыша булып чыкты. Ләкин мутация нәтиҗәләре, гомумән алганда, бер дә сөенечле якка түгел.

Яңадан-яңа, берсеннән-берсе хәтәр штаммнар яралып, соңгы хәреф – омегага ук барып җитмәбезме? Яисә аңа җиткәнче үк, Айвазовский картинасындагыча, «тугызынчы дулкын» ябырылып, безне каплап китмәсме? Вирус вәхшиләнеп, «уңыш»ны мулдан җыеп торганда, «юк» дип әйтү кыен. Тик өметсезлеккә бирелү дә дөрес түгел. Вируска, килеп эләккәндә дә, бөтенләй үк бирешмәгән кешеләр бар. Ничә авырса да, чирне җиңел кичергәннәр дә хәтсез. Монысы – беренчедән. Икенчедән, вирус таралып, ел ярым гомер үтүгә үк кешелек дистәләгән төрле вакцина тудыра алды. Аларны зәхмәткә каршы суперчара дип әйтеп булмый, әлбәттә. Тик аны кадаткан очракта сине, авыл кешесе әйтмешли, каенлыкка озату ихтималы бермә-бер кими. Авырып киткәннәрне дә медицина, начармы-яхшымы, дәваларга өйрәнде. Әмма тулы җиңүгә әле бик иртә.

> **Сан**
>
> • Соңгы мәгълүматлар буенча, Россиядә коллектив иммунитет дәрәҗәсе **45,7** процентка җиткән. Вакцина ясатучылар саны – **53,5** млн кеше. **49,1** млн кеше прививканың икенче дозасын алган.
>
> • Татарстанда исә барлыгы **1426700** кеше коронавируска каршы вакцина ясаткан. Бер тәүлеккә үсеш – **31300** кеше. Вакцина ясатучыларның **1008592**се прививканың икенче дозасын алган.

Кешелек көрәштә. Ул көрәшнең әле гел башка ягы да бар. Вакцина ясатырга теләмәгәннәр белән дә якалаш бара. Алар һәр илдә дә бар. Һәр илдә дә сарык бәрәне кебек кире һәм үҗәтләр. Аларны вирус ялчылары дип атау да дөрес булыр иде. Чөнки андыйлар үз гомерләрен куркыныч астына куеп кына калмый, башкаларны да чир белән исәпләшмәскә, прививка ясатмаска, битлек кимәскә өйрәтә, өнди. Һәм алар гади халык арасында гына түгел. Телефонга килгән видеога ышанганда, Белоруссия Президенты үзе үткәргән киңәшмәдә илнең сәламәтлек саклау министры белән МВД җитәкчесен пешекли. «Нигә дип халыкка көчләп битлек кидерәсез, кимәгәннәрне ник җәберлисез, штраф саласыз?» Усал чырай, рәхимсез эпитетлар. Бу – Лукашенконың вируска, ул китергән фаҗигаләргә ышанмавымы, әллә очсызлы популизммы, аңламассың да. Дәүләт җитәкчеләре шулай кылангач, калганнарны ничек игә китерергә соң?! Батька, бәлки, ковидны табигый сайланыш дип кабул итәдер? Картлар, яшен яшәгән, ашын ашаганнар китә торсын, Пенсия фондына җиңелрәк булыр, дип уйлыйдыр. Сәламәтлеге шәптән булмаганнар гүргә кереп ятса, илнең генофонды яхшырыр, диядер. Ә бер матур гына көнне үзе яисә якыннарыннан берәрсе авырып китеп, яшәү белән үлем арасында калса, ул ни кыланыр иде. Ковид-диссидентларның (аларны антиваксерлар дип тә атыйлар) күбесе шундый бәла килгәнен көтә, күрәсең. Урысча әйткәндә, «Пока жареный петух не клюнет».

Халыктагы ваемсызлык хәттин ашкан. «Җиде көн» тапшыруында Илшат Әминов бик тә хаклы рәвештә халыкны биомассага, көтүгә тиңләп: «Көтү исән калсын өчен аның ким дигәндә 60 процентын вакцинацияләргә кирәк. Аңламаучылар, провокаторлар күп булу сәбәпле, бу эшне мәҗбүри башкару зарур, аны никадәр тизрәк башкарсак, шулкадәр күбрәк гомерләрне саклап калачакбыз», – дигән иде. Дөрес сүзләр. «Кеше – җәмгыятькә берләшкән хайван» («Человек – общественное животное»). Моны беренче булып Әминов түгел, ә Аристотель әйткән. Без барыбыз да Аристотель әйткән җан иясе булган тәкъдирдә, тегеләр – миллионнарны бакыйлыкка озатырга өлгергән пандемияне күрергә теләмәгән кавем, кем әйтмешли, хайванның да хайваны. Татар әйтемен искә төшергәндә, бөтен көтүне пычратучы шакшы сыерлар. Илләр, дәүләтләр аларны авызлыкламаган очракта грек алфавиты безгә тәгаен җитмәячәк. Бер Казан табибы тәкъдим иткәнчә, вакцина кадатмаганнар авырганда, аларны бушка түгел, ә үз хисапларына дәвалыйсыдыр, бәлки?

Ачыктан-ачык антиваксер булмыйча, пошмаган, чир мине урап узар, дип йөргәннәр дә җитәрлек. Андыйлар ковид-диссидентлардан әле бәлки күбрәктер дә. Җәен дә, көзен дә туйлар гөрләде, чираттагы елларда чирсез замандагыча җыелу, аралашу, кунакка йөрүләр, туган көннәрне бар булган дуслар белән җәелеп китеп, дөньяны онытып үткәрүләр, сәүдә үзәкләреннән кайтып кермәү – ваемсыз халык барысын да эшләде. Прививка пунктларына барып кайту хакында гына онытты. Нәтиҗәсе: сентябрьдә көненә 17–18 мең кешенең чирләп китүе теркәлсә, бүген ул сан 36 мең чиген узды. Соңгы бер атна эчендәге үсеш кенә дә 6 мең чамасы. Математиканы аз-маз белгән кеше өчен бу – арифметик прогрессия. Сансызлыгыбызны 2022 елга да алып кергәндә, тагын да кабахәтрәк, булган вакциналарны бар дип тә белмәгән штамм тудырмабызмы? Үзен акыллыга санап йөргән кавемне иманга китерү өчен чирнең геометрик прогрессия буенча, аннан да кызурак таралуы, үләт чире заманнарындагы кебек, чебен кебек кырыла башлау, урамнарда мәетләр яту кирәкме? Ваемсызлыкның чиге булсын иде.

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Үтәлгән васыять

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Әбрар Җәләлиевнең бертуганының кызы Роза ханым, бу хәбәрне ишеткәч сөендек, ди. Ышанмаслык та, дулкынландыргыч та яңалык була бу аларның нәселе өчен.

– Бу вакытта Казанда идем. Эзтабар Лев Николаевич шалтыраткач, елап та җибәрдем. Елыйм да елыйм, күргәнебез булмаса да, үз әтиемдәй бит ул. Туган ягына алып кайтып күмү өчен сезнең ризалык кирәк, диде эзтабар. Әлбәттә, ризалаштык. Безнең өчен зур вакыйга бит бу, – диде ул. – Әбрар абыебыз туганнар каберлегендә җирләнгән, дигән хәбәрләр дә булды. Ул чорда кешеләр күпләп үлгән бит инде. Белеп тә бетермәгәннәрдер... Сугыштан безнең әти генә исән кайта шул.

Әбрар Җәләлиевнең сеңлесенең оныгы Ләйсән Медова әйтүенчә, татар солдатына Советлар Союзы Герое исеме биреләчәк дигән хат та килгән булган.

– Ул заманда аның артыннан йөрүче булмаган шул. Әбрар абыйның җәсәде табылуын белгәч, бик дулкынландым, шатландым һәм горурлык хисе тойдым. Ул пөхтәлекне ярата торган таләпчән нәселдән, шуңа да командир булгандыр. Әлеге эштә катнашкан кешеләргә зур рәхмәтебезне белдерәбез, – диде ул. – Әле дә һәрбер гаиләдә бабайларын, абыйларын көтеп яшәгәннәр бар. Һәркемгә дә безнеке кебек хисләрне кичерергә теләр идек. Аларны да тапсыннар, хөрмәтләп соңгы юлга озатсыннар иде.

Кайбычның «Туган якны өйрәнү музее» җитәкчесе Илдар Шакиров әйтүенчә, аларның буыны Әбрар Җәләлиев исемен ишетеп тә, белеп тә, укып та үскән. «Китапханә җитәкчебез һәр 9 Май саен Әбрар абый истәлегенә берәр чара оештырмый калмый иде. Бер китап та бар иде әле, аның артында «Герой исеме бирелмичә калган герой» дип, Әбрар абый хакында да язылган иде. Шуны таба алмыйбыз, эзлибез. Әбрар абыйның шәхси әйберләрен туганнары музейга тапшырды. Ул лаеклы урынын табар. Киләчәк буынга үрнәк булыр. Районның иң кыйммәтле экспонаты итеп сакларбыз», – диде ул.

P.S. Язмышның кайчагында рәхимле булуы шушыдыр инде: солдат кайтуын туган ягы да көткән диярсең! Ул «узасы» авыл урамына күптән түгел генә ак таш түшәлгән булган. Әбрар Җәләлиевнең дә рухы шат, җаны тынычлангандыр инде хәзер.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Академик В.М.Бехтерев исемендәге Республика клиник психиатрия хастаханәсе җитәкчелеге һәм коллективы, Яшел Үзән шәһәренең психо-неврологик диспансеры участок табибы-психиатр

СЕНЮШИНА Наталья Николаевна

вафат булу сәбәпле, мәрхүмәнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Спорт

Егетләргә авыррак булачак

Россия Олимпия комитеты киләсе елның февралендә Пекинда узасы Кышкы Олимпиадага барырга мөмкин спортчыларның исемнәрен атады. 599 кандидат арасында Татарстаннан 20 спортчы бар. Күбесе – хоккейчылар. Дөрес, аларга Олимпиадага барып җитү җиңел булмаячак.

Татарстаннан Олимпиадага бару өчен әзерләнәчәк спортчыларның 5е – чаңгычылар. Болар – Кристина Мацокина, Анна Нечаевская, Андрей Ларьков, Артем Николаев һәм Антон Тимашов. Билгеле булганча, соңгы елларда республикада спортның бу төренә аерым игътибар бирелә. Нәтиҗәсе дә юк түгел. Әйтик, Андрей Ларьков моннан 3 ел элек Пхенчханда узган Олимпия Уеннарында эстафетада – көмеш, 50 чакрымлык узышта бронза медаль яулады. Ул әле дә Татарстандагы ир-егет чаңгычылар арасында иң көчле спортчы санала. Дөрес, узган сезон 32 яшьлек чаңгычы өчен уңышлы булмады. Ул коронавирус белән авырды. Шуның аркасында халыкара ярышларда чыгыш ясый алмады. Россия чемпионатында исә март аенда ике бронза һәм бер алтын медаль отты. Анна Нечаевскаяның да Пхенчхан Олимпиадасында эстафета ярышында откан бронза медале бар. Әмма узган кыш Анна өчен дә уңышлы булып санала алмый. Кристина Мацокина узган сезондагы иң яхшы нәтиҗәсенә юниорлар арасында дөнья беренчелегендә иреште. Анда ул икенче урынны алды. 25 яшьлек Антон Тимашов исә Россия Кубогы финалында скиатлон ярышында беренче урынны алды.

Чаңгы белән трамплиннан сикерү ярышларына Лениногорскидан 25 яшьлек Данил Сабриев әзерләнә. Пекинга барачак сноубордчылар исемлегенә исә Милена Быкова, Виктор Вайлд, Дмитрий Сарсембаев, Владислав Хадарин эләгергә мөмкин. Милена Быкова моннан 3 ел элек Пхенчханда узган Олимпия Уеннарында да чыгыш ясаган иде. Анда ул үз төрендә 10 нчы булды. Аның каравы ике ел элек Красноярскида узган Универсиадада алтын һәм көмеш медальләр яулады. Бу исемлектә иң танылган кеше, әлбәттә, Виктор Уайлд. АКШта туып-үскән әлеге спортчы Россия җыелма командасы өчен чыгыш ясап, Сочи Олимпиадасында чемпион исемен яулады. Төп геройларның берсе дип игълан иттеләр. Чөнки аңа кадәр Россия сноубордчыларының мондый уңышка ирешкәне юк иде. Дөрес, соңгы елларда ул медальләр белән сөендерә алмады. Ә 2019 ел ахырыннан Виктор Уайлд Татарстан спортчысы булып санала.

Фигуралы шуу ярышларында чыгыш ясаучы Евгения Тарасова исә әле ике көн элек кенә АКШтагы Гран-при турнирында Владимир Морозов белән бергә җиңү яулады. Алар әле дә Россиядә иң көчле парлардан санала. Фигуралы шуу ярышларына әзерләнәчәк спортчылар арасында тагын бер якташыбыз бар. Камилә Вәлиева – дөньяда иң өметле спортчыларның берсе. Казанда туып-үссә дә, туташ Мәскәү спортчысы санала.

Пекинга бару ихтималы булган хоккейчылар арасында 119 спортчы бар. Шуларның 9ы – «Ак барс» вәкилләре. Болар – капкачылар Тимур Билалов белән Игорь Бобков, сакчылар Даниил Журавлёв, Никита Лямкин, Дмитрий Юдин, һөҗүмчеләр Дмитрий Воронков, Артём Галимов, Николай Коваленко һәм Илья Сафонов. Олимпиадага кайсы барып җитә алыр? Катлаулы сорау. Чөнки тренерларның өстенлекне НХЛда чыгыш ясаучы егетләргә бирәсен чамалавы кыен түгел. Океан аръягындагы хоккей түрәләре берәр сәбәп табып, үзләрендәге хоккейчыларны Пекинга җибәргән очракта, әлбәттә. Аларга рөхсәт бирелсә, КХЛда, ягъни Россиядә уйнаучыларга аеруча тырышырга туры киләчәк.

ak-bars.ru

Пекинга бару бәхете «Ак барс» капкачысы Тимур Билаловка елмаермы?

Хоккейчылар исемлегендә 46 хатын-кыз да бар. Араларында якташларыбыз да аз түгел. Әмма, республикада хатын-кыз хоккей командасы булмау сәбәпле, барысы да башка төбәкләрдә уйный. Димәк, аларның спортчысы булып санала. Шулай да исемнәрен искә төшерү артык булмас. Пекинга Кукмарада туып-үскән Фәнүзә Кадыйрова, Ландыш Фәләхова (Саба), Лиана Ганиева (Актаныш), Ольга Сосина (Әлмәт) барырга мөмкин.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА
РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

ШӘЛЕ УҢГАННАРЫ:

«КҮМӘК ЭШЛӘГӘНДӘ АВЫРЛЫГЫ ЮК»

Үзем күрдем

Авылларда каз өмәләре башланды. Элек кош-кортларны суяр өчен кар төшкәнен көтә идек. Хәзер саклар урын булгач, казлар өлгерүгә урнаштыра да башлыйлар. Питрәч районының Шәле авылында яшәүчеләр каз-үрдәкләрне сатып та бетерәләр икән инде. Шушы көннәрдә без Сафиннар хуҗалыгында өмәдә булдык.

Ел саен – йөзәр кош

Сафиннар гаиләсе һәр елны 100 каз, 100 үрдәк, 100 тавык ала икән. Кош-кортлары үзләре өчен дә, кунәчкә дә, сатарга да җитә. Үрдәк белән тавык күптән эшкәртелеп суыткычка кергән инде. Өмәгә казларның да кырыгы гына калган иде.

– Авыл җирендә эшсез торып булмый. Терлек тотабыз. Тормыш җитеш булсын дип тырышабыз. Ирем Илнур белән өч ул үстердек. Бер малаебыз – хәрби кеше. Ул гаиләсе белән читтә яши. Безнең янга елга бер генә кайта. Калган улларым да үз гаиләләре белән шәһәрдә торалар. Шөкер, гел кайтып, ярдәм итеп торалар. Эшне бергә эшлибез, – ди хуҗабикә Наилә апа.

Каз өмәсенә ике килене дә кайткан. Берсе – Питрәч кызы, икенчесе Казанныкы икән.

– Шәлегә килен булып төшсәң, бөтен эшкә өйрәнәсең. Алсу, мин – шәһәр кызы, дип тормады – чүбен дә утый, каз да йолкый. Бөтен эшне әни белән бергә эшлиләр, – ди Алсуның ире Ленар. Кече килен Аида исә каенанасы яныннан китми дә. Өмәгә килүчеләрне көткәндә берсе бәлешен ясый, икенчесе аш сала, өченчесе коймак изә. Без сөйләшеп, танышып йөргән арада, урамның теге очыннан гармун тавышы ишетелде. Баксаң, өмәчеләр бар йоласына туры китереп җыела икән.

– Матур итеп каз өмәсе уздыру теләге күңелемдә әллә кайчаннан йөри иде. Без бит шушы йолалар белән үскән буын. Элек мондый чаралар бигрәк күңелле уза иде. Районның «Ак калфак» оешмасы җитәкчесе Лилия Гатиатуллина, Наилә апа, әйдә әле, яшьләргә өмә уздырып күрсәтик, дип шалтыраткач, бик теләп риза булдым. Әйтерсең, яшьлеккә кайттым. Ял көнен җиткерә алмыйча борчылдым. Эштән курыкмыйбыз анысы, әмма зурлап өмә уздырудан бераз курыккан идем, – ди Наилә апа.

Җырлап йөрү берни түгел, йола яшәсен!

Биредә бар да башкача. Питрәч районының Чыты мәдәният йорты мөдире Миннур Шәмсетдинов, бездә башта эшләтәләр, аннан сыйлыйлар, дисә, монда исә башта кунак итәләр икән, ди.

– Бигрәк матур йоланы торгызырга алынганнар. Хәзер кешедә каз да күп, әмма берсенең дә мәшәкатьләнеп бәйрәм ясыйсы килми. Тизрәк эшләү ягын карыйлар, – ди ул. Миннур, күрше авылларында каз өмәсе узасын белгәч, үзе белән ике авылдашын да алып килгән. Берсе – гармунчы, икенчесе – җырлап йөрүче егет.

Җырлау дигәннән, өмәгә килүчеләрнең күбесе «Зөбәрҗәт» халык ансамбленә йөрүчеләр икән.

– Максатыбыз – милли йолаларны кайтару. Без җырлап-биеп кенә йөрмибез. Авылыбыз үзенчәлекле. Шәледә генә булган күркәм гадәтләр бар. Шуларны саклап калу өчен ансамбль төзедек тә инде, – ди Шәле мәдәният йортының сәнгать җитәкчесе, ансамбль җитәкчесе Зөлфия Гыйниятова.

Ансамбльгә йөрүчеләр бар эшкә дә оста булып чыкты. Казлар күз ачып йомганчы йолкынды. Берәү канатын кисә, икенчесе тәпиен урнаштыра, өченчеләр эч-башын ала. Кыскасы, Шәле кызларыннан эш курка.

– Җырлап эшләгәндә, бер эшнең дә авырлыгы сизелми. Татар халкы борчуы булса да, сөенечле чагында да җырлаган. Без дә шулай яшибез. Ансамбльгә 16 кеше йөрибез. Милли йолаларыбызны кайтарасы килә. Оныкларга күрсәтеп, киләчәк буынга шуны җиткерәсе иде, – ди Эльвира Нәҗмиева. – Безнең авыл элек-электән үзенең гореф-гадәтләре, йолалары белән башкалардан аерылып торган. Авылыбыз егетләренең 80 проценты кызны урлап алып кайта. Борынгы йолага тап төшермибез. Элек инде эләктергән дә алып кайтып киткән булса, хәзер очрашып йөргән кызны бераз кисәтебрәк куялар да урлыйлар. Кызны башта егетнең берәр туганына алып кайталар. Ул анда өч көн тора. Аннан соң аны егет өенә алып кайталар. Йортка килен каз мамыклы мендәрләргә басып керә. Кызны урлауга, таң атканын көтәләр дә, егетнең әти-әнисе булачак кода-кодагыйларына барып, без сезнең алда гаепле инде, кызыгызны урладык, дип әйтә. Бик сирәкләр генә риза булмый. Аның каравы урлап өйләнүче никахлар нык була.

«Кечкенәдән белсеннәр!»

Районның «Ак калфак» оешмасы җитәкчесе Лилия Гатиатуллина исә, милли йолаларны сабый чактан ук өйрәтергә кирәк, дигән фикердә.

– Милләт яшәсен өчен без гореф-гадәтләрне сакларга тиеш. Без эшне балалар бакчасыннан башладык. Иң элек «Татар малае», «Татар кызчыгы» дигән бәйгеләр уздырдык. Һәр бәйге үз эченә күп кенә милли йолаларны сыйдыра. Әнә шулай итеп, каз өмәсенә дә килеп җиттек. Яшь буын белеп үссен, дибез, – ди Лилия. – Соңгы арада милли киемгә дә өстенлек бирүчеләр артты. Сабантуйларга хәзер бер горурлык белән чыгабыз. Күңелгә рәхәт. «Ак калфак» ул хатын-кызларны берләштереп кенә калмый, гаиләнең иминлеген дә ныгыта, балаларга дөрес тәрбия бирергә дә ярдәм итә.

Питрәч районының мәдәният бүлеге җитәкчесе Азат Фазылҗанов та, халыкны яңадан йолаларны сакларга өйрәтү җиңел түгел, ди.

– Милли оешмаларда, мәдәният йортларында татар җанлы кешеләр эшләве кирәк. Әгәр үз милләте дип янып торучылар була икән, гореф-гадәтләр беркая да югалмый. Әнә бүген дә, ял көне инде, дип тормадык, һәркем өмәгә килде. Каз йолкыганны күргән бар ул, шул өмәне матур итеп күрсәтүләр инде онытылган иде. Шәле халкына рәхмәт. Алар эшли дә, ял итә дә белә, – ди ул.

Каз өмәсенә Шәле авылы егете, язучы Камил Кәримов та кайткан иде.

– Ни дисәң дә, элеккеге каз өмәләре сагындыра. Әгәр авылларда әлеге йоланы торгызып, матур итеп бәйрәм ясыйлар икән, әлбәттә, бу бик яхшы. Әмма хәзер кешеләр үзгәрде. Алар бәйрәмгә вакыт тапмый. Каядыр ашыга, дөнья куа. Өмә ясау җиңел эш түгел. Үз мәшәкате бар. Аны кире кайтару халыктан тора. Кушып кына берни эшләп булмый, – ди Камил Кәримов. – 1990 нчы еллар башында Казанның цирк бинасында республикакүләм каз өмәсе узды. Анда төрле районнардан киләләр иде. Ул чакта товарларның юк чагы. Каз өмәсендә исә шуларны аукционга куеп сату гадәте бар иде. Шунда җырчы Венера Ганиеваның бик затлы тун алганы истә калган.

Шәле халкының уңганлыгына сокланып кайттым. Үзләре җырлый, үзләре каз йолкый. Шул арада өйдәгеләр мичтән бәлеш ала. Табада коймаклар чыжлый. Аларны каз маена манып табынга куялар. Каз йолкучыларның да эше тәмамлана. Казларны чишмәдә чайкап менеп, алар башка йортка ашыга. Үзләре әйтмешли, күмәкләп эшләгәндә каз йолку сизелми дә икән ул!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

СӘНГАТЬЛЕ МАРАФОН

«КИТАП» РАДИОСЫ ТАТАРСТАН ҺӘМ БАШКОРТСТАН РАЙОННАРЫ БУЙЛАП СӘФӘР ЧЫКТЫ

Казан – Уфа – Казан маршруты буенча... матурлык эзләргә! Татар-башкорт арасындагы дуслык җепләрен ныгыту, татар әдәбиятын, җыр сәнгатен халыкка җиткерү. «Китап» радиосы әнә шундый максатлар белән өч көнлек сәфәргә китте.

25–28 октябрьдә Татарстан һәм Башкортстанның 18 районында «Мин матурлык эзләп йөрим...» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә узачак. «Китап» радиосы Татарстанның Мамадыш, Алабуга, Чаллы, Минзәлә, Актаныш, Азнакай, Әлмәт районнарында, Башкортстанның Дүртөйле, Илеш, Бакалы, Чакмагыш, Кушнаренко, Чишмә, Бүздәк, Туймазы, Октябрьский районнарында тукталыш ясарга ниятли. «Безнең төп максат – кыска гына вакыт эчендә Уфага барып җитү. Шуңа да без юл өстендә калучы районнарны сайладык», – ди «Китап» радиосының баш мөхәррире Алмаз Миргаязов. Радионың атрибутикасы сурәтләнгән яшел автобус күрсәгез, аптырап калмагыз. Димәк, сезгә җыр-моң вә шигърият алып киләләр.

Тукталышларда радио алып баручысы һәм башкарма продюсеры Лилия Кадыйрова Роберт Миңнуллин, Әнгам Атнабаев, Эльмира Җәлилова һәм башка күренекле авторларның шигырьләрен укыячак. Ильяс Минһаҗев җитәкчелегендәге «MINGAZOV» кавер төркеме исә һәр татар һәм башкорт халкына электән таныш җырларны башкарачак. Тамашачылар үзләре дә чыгыш ясый алачак.

«Китап» радиосының мобиль кушымтасын инде 23 меңгә якын кеше куллана икән. Әлегә радионың FM-ешлыгы Казанда гына бар. Күпләр аның башка шәһәр һәм районнар өчен дә барлыкка килүен көтә икән. «Бу турыда көн дә сорап язалар. FM-ешлык булдыру – шактый катлаулы һәм чыгымлы эш. Ә безнең әлегә мондый мөмкинлегебез юк. Аннан соң, хәзер бит күпләр мобиль кушымталарны кулайрак күрә», – дип сөйләде безгә Алмаз Миргаязов.

«Мин матурлык эзләп йөрим...» дип аталган кичәне Казан тамашачысы күрергә өлгерде инде. Ул чакта мондый форматны шактый җылы кабул иткәннәр иде. Татар әдәбиятын, традицион җыр сәнгатен популярлаштыру, халыкка яңгырату, кешеләрдә шигърияткә мәхәббәт уяту – яшь башкаручыларның максатлары зурдан. «Китап» радиосы оештырган автомарафон исә моннан тыш Татарстан һәм Башкортстан арасында дуслык җепләрен ныгыту, кешеләрнең күңелләрендә бер-берләренә карата ихтирам, мәхәббәт, сабырлык тәрбияләү максатларын да күз уңында тота.

– Гасырлар буена дус булып яшәгән күршеләр – башкорт һәм татар мәдәниятенең никадәр якын булуын, тыңлаган җырларыбыз, укыган шагыйрьләребезнең ни дәрәҗәдә уртак булуын күрсәтергә телибез. Без – бер үк җырларны тыңлап, бер үк шагыйрьләр, язучылар иҗатында тәрбияләнгән кешеләр, – ди бу турыда Алмаз Миргаязов.

«Татар-информ»/Салават Камалетдинов

Радио җитәкчесе шулай ук әлеге автосәяхәтнең тагын бер мөһим максатына тукталды: «Китап» радиосының төп мәгънәсен тәшкил иткән матур сүзне, һәрбер өйгә таныш көйләр, милли моңнар һәм китапны пропагандалау. Районнан-районга, авылдан-авылга кереп мондый радио барлыгын да белгертәселәре килә. «Китап» радиосы Кырымга кадәр барып җитәргә тели. Самара, Саратов, Әстерханда яшәүче милләттәшләребез белән очрашу теләге дә бар.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7405 данә
Гомуми тираж – 17243 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 356

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+